КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 октябрь г.Казань № 1233

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 11 июнь, 549 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге сүзләрне өстәргә:

татар текстында «җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге)» сүзләреннән соң «, алына торган җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенә (җир кишәрлекләренә) алыштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы һәм җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлеген алу турында» 2022 ел, 24 май, 483 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктка түбәндәге сүзләрне өстәргә:

татар текстында «җир кишәрлеген (алга таба – алына торган җир кишәрлеге)» сүзләреннән соң «, алына торган җир кишәрлеген Татарстан Республикасы милкен-

дәге җир кишәрлегенә (җир кишәрлекләренә) алыштыру юлы белән» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта:

алтынчы һәм җиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«алына торган җир кишәрлегенең һәм Татарстан Республикасы милкендәге җир кишәрлегенең (җир кишәрлекләренең) базар кыйммәтен бәяләгәннән соң, 30 көн эчендә җир кишәрлекләрен алышу шартнамәсен (алга таба – шартнамә) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлеге милекчесенә җибәрүне;

шартнамә төзүне;»;

сигезенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

унынчы абзацта «килешү» сүзен «шартнамә» сүзенә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин